Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 7**

Балыклы-Чүкәй авылы 18.06.2025

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы депутатларын бишенче чакырылышка сайлауны билгеләү турында

Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында" Федераль законының 10 статьясының 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасының Сайлау кодексының 6 статьясының 2 өлеше, 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы депутатларын бишенче чакырылышка сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны "Авыл Офыклары"-"Сельские горизонты" газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Татарстан (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көненнән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Глава Балыклы-Чукаевского
сельского поселения
Рыбно-Слободского
муниципального района
Республики Татарстан И.С.Мазитов